# ПЕНЗА ӨЛКӘСЕ ҺӘМ МОРДОВИЯ РЕСПУБЛИКАСЫ ТАТАР-МИШӘРЛӘРЕ ЙОЛА ФОЛЬКЛОРЫ ӨЙРӘНЕЛЕШЕ

Флера СӘЙФУЛИНА
Филол. фән. докторы, проф., Казан федераль университеты, Казан
fsaifulina@mail.ru

# STUDY OF RITUAL FOLKLORE OF TATARS OF THE PENZA REGION AND THE REPUBLIC OF MORDOVIA

**Flera SAYFULINA**
Philol. ph. Doctors, prof., Kazan federal universities, Kazan

**SUMMARY**

For centuries, the Tatars lived in different parts of Russia. Today they live in such places as the Republic of Bashkortostan, the Chuvash Republic, Western Siberia, Orenburg, Ekaterinburg, Ulyanovsk, Nizhny Novgorod, Penza, Samara, Saratov, Tambov, and others. Folklorists are interested in oral folk arts, in customs and traditions of the people living in these areas, which were formed under the influence of geographical conditions, and the influence of neighbours. During the 20th century, there was a great activity aimed at collecting folklore of Tatars living in different parts of the country. To this end, various expeditions were organized, the collected materials were studied, they also were classified according to the genre, and textbooks, anthologies, multi-volume books were published. This article is devoted to the analysis of the folklorists' study of the traditions of the Tatars living in the Mordovia Republic and Penza region.

There are typical characteristics peculiar to the Tatars from other regions in the works of oral folk arts, preserved in the language of Mishar in the Mordovia Republic and Penza region, as well as there are works

different from the others. Folklore of this area is studied in detail and separately and in the context of the folklore of the Tatars in other regions.

In the social and cultural life, following the traditions, customs and holidays is common to each nation. This is an important element of culture, it has an ethnic component and proves a connection with the ancient features of the nation. From this point of view, ritual folklore in the center of many scientists’ attention. Lexical units related to this genre are studied by linguists, and observance of rituals and traditions is carefully studied by folklorists.

Татар халкы Татарстаннан тыш гасырлар буенча Россиянең төрле төбәкләрендә сибелеп яши. Бүенге көнгәчә татарлар Башкортстан, Чувашстан Республикаларында, Көнбатыш Себер, Ырынбур, Свердлау, Ульян, Түбән Новгород, Пенза, Самара, Сарытау, Тамбов һәм башка өлкәләрдә гомер итә. Әлеге җирләрдә яшәүче халыкның географик урыннары, яшәү шартлары, күршеләре тәэсирендә формалашкан үзенчәлекле гореф-гадәтләре, авыз иҗаты әсәрләре фольклорчы галимнәр игътибарын үзенә тарта. XX гасыр дәвамында төрле төбәкләрдә яшәүче татар кауменең фольклор әсәрләрен туплау-язып алуга юнәлдерелгән экспедицияләр оештыру, тупланган материалны аерым алып өйрәнү, җанрлар буенча классификацияләү, дәреслекләр, хрестоматияләр, күптомлыклар бастырып чыгару юнәлешендә җитди эш алып барылды. Әлеге мәкалә Мордовия Республикасы һәм Пенза өлкәсе татарлары йола фольклорының галимнәр тарафыннан өйрәнелешенә багышлана.

Пенза өлкәсе һәм Мордовия Республикасы мишәрләре телендә сакланып калган фольклор әсәрләрендә төрле регионнарда яшәгән татар халкына хас булган сыйфатлар да, шулай ук, башкалардан аерып торган эчтәлекле әсәрләр булуы да табигый. Әлеге төбәк фольклоры

фольклорчылар тарафыннан аерым алып та, башка төбәкләрдә яшәүче татарлар авыз иҗаты жанрлары контекстында да шактый өйрәнелгән.

Иҗтимагый-мәдәни тормышта билгеле бер йолаларны үтәү, гореф-гадәтләр тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык халыкларга да хас күренеш. Ул мәдәниятнең мөһим элементы булып исәпләнә һәм аның аермачык этник төстә булуы, халыкның бик борынгы үзенчәлекләренә бәйлелеге күзгә ташлана. Бу яктан караганда йола фольклоры күп галимнәрнең игътибар үзәгендә тора. Бу җанрга караган әсәрләрнең лексик атамалары тел галимнәре тарафыннан өйрәнелсә, йола, традиөияләрнең үтәлеше фолҗклорчылар тарафыннан тәфсилләп өйрәнелгән булуы белән аерылып тора.

Татар халык авыз иҗатының иң кызыклы, катлаулы һәм авыл халкының яшәү рәвешен, тормышка мөнәсәбәтен чагылдыра торган төренең берсе – йолалар. Йола фольклоры – халык иҗатының иң борынгы төрләреннән берсе. Галимнәр халык йолалары белән бәйле телдә сакланып калган әсәрләрне икегә бүлеп карыйлар: ел фасыллары дәвамында башкарыла торган хуҗалык эшләренә бәйле календарь йолалары; гаилә-көнкүреш йолалары. [Бакиров, 2012: 50]

Мордовия татар- мишәрләрендә табигать культы турында аерым мәгълүматлар В.Рогачев мәкаләсендә Мордовия халыклары белән чагыштырма аспектта карала [Рогачев, 2003: 154-157]. Бу хезмәттә сөйләм үрнәкләре буларак тәкъдим ителгән текстларда яңа елны каршылау, авыл хуҗалыгы эшләре белән бәйле йолалар, төрле өмәләр, аулак өйләр һ.б. турында мәгълүматлар табарга мөмкин.

Пенза өлкәсеннән җыелган материаллар арасында төрле бәйрәмнәр уңаеннан күрәзәлек итү – киләчәкне алдан күреп юрау, аның төрле формалары, нардуган, нәүрүз вакытында теләкләр теләү, теләккә чыгу (яңгыр теләге), изгеләр каберенә барып теләк теләү кебек йолалар – шуларның бер чагылышы булып исәпләнергә хаклы. Пенза өлкәсендәге (Пенза өлкәсе, Каменка районы, Кикино авылы)

мәгълумат җыючылар Арслан Полка исемле кешенең кaберенә мөнәсәбәтле ышану һәм йолаларга еш туктала. Бу тарихи шәхеснең каберлегенә куелган чардуганга күпсанлы кулъяулыклар бәйләнгән. Җирле халык моны кабер иясенең изге җан булуы белән аңлата, каберлектә шушындый хәер калдырып, теләк телисең, үтенечеңне сөйлисең икән – теләкләрең тормышка ашачак дип ышаналар. Бу шәхес хакында телдә күп легендалар яши, аларның күбесе К. Акъегетнең «Пенза татарлары» [Акъегет, 2001: 140] китабында дөнъя күрә.

Гаилә-көнкүреш йолаларына бала туу белән бәйле, никах туе, кешене соңгы юлга озатуга мөнәсәбәтле йолалар комплексы, кузайтын (каршы алу), хәрби хезмәткә озату һ.б. бәйрәмнәр керә. Билгеле булганча, гаилә-көнкүреш йолаларыннан *туй йолас*ы иң күренеклесе. Халыкның гаилә коруга җитди мөнәсәбәте, тормыш төзү кануннары бик борынгыдан формалашып, милли яшәү рәвеше буларак оешкан һәм туй йолаларында чагылыш тапкан.

Татарларның башка этник төркемнәре кебек үк, татар-мишәрләрнең туй йолалары фольклорчы галимнәрнең игътибар үзәгендә тора. Бу юнәлештәге хезмәтләрдән, Р.К. Уразманова [Уразманова, 2001: 196 ], Ф.С. Баязитова [Баязитова, 1992: 295; 1995: 56; 2003: 288] Р.М. Мөхәммәтҗанов [Мөхәммәтҗанов, 1977: 11; 1990: 156], З.М. Арикеева-Брусько [Брусько, 2012: 21] һ.б. хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин. Туй йоласы фольклорчылар, этнографлар тарафыннан да яратып, тәфсилләп, шактый өйрәнелгән өлкә. Фольклор һәм шигърият белгече М.Бакировның соңгы елларда дөнья күргән җитди, саллы хезмәтләрендә дә бу юнәлештә эзләнүләр аерым урын алган. [Бакиров 2008: 359; 2012: 400] Бу хезмәтләрдә Пенза, Мордовия татар-мишәрләренең халык иҗаты үрнәкләренә дә шактый урын бирелгән.

Төрле этаплардан торган катлаулы бер күренеш буларак Мордовия мишәр-татарларының туй йоласы М.М.Акашкин хезмәтендә Мордовия халкы туйлары белән чагыштырма аспектта өйрәнелә. [Акашкин, 2000: 154]. Хезмәт туй йолаларын үтәү вакытында башкарыла торган җырларны өйрәнүгә багышланган булса да, эшнең шактый өлеше туй йолаларын характерлауга, үзенчәлекләрен, бүгенге көндә сакланылыш дәрәҗәсен күзәтүгә багышлана.

Р.Мөхәммәтҗанов билгеләвенчә: «Туй йолаларының төп юнәлеше һәм составы бер йорттан икенче йортка кыз (кәләш) тапшыру, булачак ирнең йортына озатудан тора. Калган бөтен эшләр (башта, озатканда, соңыннан булган чаралар) һәммәсе дә әлеге үзәк акт – ярәшелгән кызны күчерү – тирәсенә тупланган». [Мөхәмәтҗанов, 1977: 11] Бу процесс күпчелек халыкларда һәм татарларда да шулай булган һәм берничә көнгә яки айга сузылган. Шул рәвешле катлаулы фольклор-этнографик комплекс барлыкка китерелгән.

Кеше гомерендә иң әһәмиятле урын тоткан туй, бала туу һәм кешене мәңгелек дөньяга озату белән бәйле йолалар татар халкының гомер юлындагы иң әһәмиятле этапларны үз эченә ала. Ф.С. Баязитованың алда телгә алган “Гомернең өч туе” [Баязитова, 1992: 295] китабы чагыштырма аспектта төзелгән булуы ягыннан үзенчәлекле. Бу хезмәттә төрле регионда яшәгән татар-мишәр халкының гаилә-көнкүреш йолалары терминологиясе кулланылышы, мәгънәсе хакында аңлатма бирелә, аларның үзенчәлекләре, вариантлары тәкъдим ителә. Китапта галимә Мордовия һәм Пенза татар-мишәрләре йолаларын да терки. Шундыйлардан, Мордовия татарлары йолаларына хас булган төшенчәләрдән, “кийәү җийу” (26 б.), “туй мунчасы” (33 б.), “еңгә” (45 б.), “шалдырдавык” (53 б.), “мәһәр” (100 б.), “кода уняу” (111 б.), һ.б.; Пенза мишәрләре теленнән язылган үрнәкләрдән “башкода” (10б.), “бузал” (18 б.), “йарашу” (18 б.), “киңәш” (20 б.), “сүз алырга килү” (23 б.), “сүз бирү, йакшы сүз

бирү” (23 б.), “ир артыннан чыгу” (23 б.), “ырланып китү” (23 б.), “никах сывы” (30 б.), “кодагигый бару” (39 б.), “арчига килү” (44 б.), “чыңгыл” (53б.), “йараш туй” , “туй келәве” (118 б.) һ.б. китерелә. Китапның туйлар белән бәйле бүлеге – эшнең иң зур өлешен тәшкил итә: аның аерым этаплары, кыз алуның хикмәтләре, яшьләр, кода-кодагыйлар мөнәсәбәте, туй киемнәре белән бәйле күптөрле төшенчәләр татар халкының тел һәм күңел байлыгын да, яшьләргә яңа тормышны башлауның никадәр җитди эш булуын да аңлатуга юнәлдерелгән. Гаилә-көнкүреш йолалары, һичшиксез, боларны үткәрү барышында әзерләнә, кулланыла торган ризыклар белән дә бәйле.

Мордовия татар-мишәрләреннән 2015 елда КФУ галимнәре һәм студентлары татарыннан язып алынган фольклор материаллары арасында туй йолалары белән бәйле шактый кызыклы мәгълүматлар бар. (Кадирова һ.б., 2015: 324) Бу җирлектә тупланган туй йоласының тәртибе, бала туу, аңа исем бирү һәм аны үстерү барышында үтәлергә тиешле йолалар, һәм, кеше вафатыннан соң башкарылырга тиешле гамәлләргә дә китапта аерым урын бирелгән.

Мордовия республикасының экспедиция оештырылган кайбер татар-мишәр авылларында туй йолаларының шактый сакланган булуы игътибарга лаек. Бу якларда туй йоласы аерым ритуалларны берләштерә. Шундыйлардан, *яучылау* өчен бирედә иң уңышлы көн дип чәршәмбе һәм җомга көн санала. Яучы булып егетнең әти-әнисе яки берәр якын туганы килергә мөмкин. Кыз бу егеткә барырга риза булса, аның әти-әнисе чәй өстәле артында яучыларга хәбәрне әйтәләр һәм *кул билгесе көнен* билгелиләр. *Ярәшү* яки кул билгесе көнне кыз йортына егетнең әти-әнисе бүләкләр белән килә. Алар булачак кодалар белән калым хакын, кызга нинди киемнәр алырга кирәклекне (елның дүрт фасылына да яраклы баш, өс, аяк киемнәре, туй, туй арты көне өчен киемнәр һ.б.) сөйләшәләр. Аларны тәмле ризыклар белән сыйлап, кызның ризалык билгесе буларак берәр бүләк, мәсәлән, сөлге биреп

озаталар. Кияүнең нинди вакытка килергә мөмкин икәнен әйтеп җибәрәләр. Билгеләнгән вакытка кияү үзенең бертуган абыйсы яки энесе, я берәр якын дусты белән килә. Кызга бүләк итеп алтын бизәнү әйбере һәм чәчәк алып килә. Аннан соң с*үз бетерү* үткәрелә, ягъни бу көнне егетнең эти-әнисе һәм якын туганнары җыелышып кыз йортына баралар. Алар барысы да яшь киленгә һәм аның әнисенә бүләкләр алып киләләр. Кияүнең әнисе кәләшкә алтын бизәнү әйберсе бүләк итә. Кодагыйлар да бер-берсенә бүләкләр бирешәләр. Сүз бетергән көнне кичен кыз өенә ике яктан да яшьләр җыела. Әлеге табынны *туй* дип йөртәләр. Бу көнне кунакка килгән яшьләрнең барысына да кызның әнисе бүләк биреп җибәрә.

Әлеге китапта туйның иң әһәмиятле булган өлеше – *никах (фатия)* турында да шактый информация бирелә. Башка җирлектә яшәүче татарлардагы кебек үк аны үткәрүдә ислам, шәригать кануннары өстенлек итә. Никах кыз өендә укыла, нигездә өлкәнрәк буын кешеләр килә. Мулла никах укыр алдыннан кыздан өч тапкыр рөхсәт сорый. Кызның уңай җавабыннан соң гына никах укыла. Кияүнең этисе мәһәрне кәләшнең кулына тапшыра. Башка яктагыдан аермалы буларак никах бәйрәмен бу якларда фатия дип атау да бар, никах укыту вакытында өстәлгә савыт белән су куела, аны “фатия суы” дип атыйлар. Никахтан соң бу су белән яшьләр кулларын, битләрен юу гадәте кызыклы, ахырдан суны агач төбенә түгәләр.

Өлкәннәр таралгач, кияү, дус егетләре кызны алырга килә. Шул вакыт мылтыктан ату йоласы да саклануы хакында информация бар. Мылтыктан ату аерым урынныйрда, мәсәлән, Себер татарларында бүгенге көнгә кадәр сакланган. Туй йоласына караган фәнни хезмәтләрдә бу күренешкә карата да фикерләр бар. Р.Мөхәмәтҗанов кияү килгәндә мылтыктан атуны борынгыдан калган йола элементы дип күрсәтә һәм борынгы кеше карашынча, усал, явыз көчләргә каршы

тору чарасы, ягъни апоторопик магиянең бүгенге көнгә килеп җиткән күрсәткече дип саный. [Мөхәмәтҗанов, 1977: 28].

Кыз өендә ашап-эчкәч, кияү, әти-әнисеннән рөхсәт сорап, кызны алып китә һәм егет ягы әзерләгән табынга – туй мәҗлесенә – *кодага* кайталар. Кодада кеше бик күп була, зурлап уйнала. Ирләр һәм хатын-кызлар аерым өстәлләр артына утыра. Яшь парлар да иң якын туганнары белән аерым утыралар. Кунаклар бераз ашап-эчкәч, яшь кәләш белән кияүне хатын-кызлар ягына «тау итәргә» ягъни, күренергә чакыралар. Күренекле галим М.Бакиров «Туй табыны җырларының берише, мәҗлес ахырында җырлана торганнары, «тау итү җырлары» дип атала. Тау итү кыпчаклардан килгән борынгы гыйбарә, рәхмәт белдерү мәгънәсендә. Мондый җырлар мишәрләрдә һәм кершен татарлары арасында күбрәк сакланган» – дип яза. [Бакиров, 2008: 79]. Туй җырлары турындагы мәгълүматлар күп чыганакларда бирелгән.

Мордовия һәм Пенза өлкәсендә яшәүче кардәшләребезнең гаилә йолаларының иң матуры – никах туе йоласын бүгенге көнгә кадәр шактый тулы формада саклап үткәрүләре һәм киләчәк буынга җиткерүләре бик матур күренеш. Әлбәттә, аерым үзенчәлекләр олы буын хәтерендә генә истәлекләр рәвешендә сакланып калган, кайбер очракларда йолаларның аерым өлешләре өлкән буын галимнәр язмаларында гына саклана.

## ӘДӘБИЯТ:


Акашкин М.М. Свадебные обряды, песни татар-мишарей и мордвы (Сравнительный анализ): дис. … канд. филол. наук. – Казань, 2000. – 154 с.

Акъегет К. Пенза татарлары: кыскача тарих, авыллар, халык иҗаты. – Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 2001. – 140 б.

Бакиров М.Х. Татар фольклоры. –Казан: Мәгариф, 2008. – 359 б.

Бакиров М.Х. Татарский фольклор. – Казань: Ихлас, 2012. – 400 б.

Баязитова Ф.С. Гомернең өч туе. – Казан: Тат.кит.нәшр, 1992. – 295 б.

Бруськo З.М. Фольклор семейно-бытовой обрядности татар / Автореф. канд. филол.наук. - Казань, 2012. – 21 с.

Мордовия Республикасы һәм Пенза өлкәсе татарлары: диалектология һәм халык авыз иҗаты материаллары / Төз.-авторлар Э.Х.Кадирова, Г.Р.Галиуллина, Ф.С.Сәйфулина, Ә.Ш.Юсупова. - Казан: Казан ун-ты нәшр., 2015. – 324 б. китабы материаллары нигезендә.

Мөхәмәтҗанов Р. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты (Туй поэзиясе) “Татар халык иҗаты” курсы буенча читтән торып укучы студентлар өчен уку әсбабы. – Уфа, 1977. Б. 11.

Рогачев В.И. Культ покровительницы воды в свадебной обрядности и в фольклоре народов среднего Поволжья // Интеграция образования, 2003. - № 2. – С.154-157.

Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. – Казань: Тат.кит.нәшр., 1995. – 156 б.

Татар-мишәр рухи мирасы: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. – Саранск: Татарская газета, 2003. – 288 б.

Уразман Р. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.